ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

24 02 2021г. № 31

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 15 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегиясе беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 480 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2018 елның 15 гыйнварындагы 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6 пунктына икенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча түләнергә тиешле бурычлар булмавы турында мәгълүмат.»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара соратуга дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына ведомство буйсынуындагы оешманың җавабы килүе.»

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Р. Салаватов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881